Республика Татарстан
Глава Старомензелябашского
сельского поселения
Сармановского муниципального
района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районының
Иске Минзәләбаш авыл җирлеге
башлыгы

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел 7 ноябрь № 5

Татарстан Республикасы Сарман
муниципаль районы Иске Минзәләбаш
авыл җирлегенең Кужак авылында
2024 елда үзара салым акчаларын кертү һәм
алардан файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар итәм:

1.Кужак авылы гражданнарның 2024 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне 2023 елның 17 ноябренә 14 сәгатькә Кужак мәдәният йортында билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, I төркем инвалидлар; олы яшьтәге ялгыз гражданнар; вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар; контракт буенча хәрби хезмәт үтүче гражданнар; өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылганнар һәм аларның гаилә әгъзалары; уку йортларының көндезге бүлекләрендә укучы студентлар; хөкем ителгәннәр; авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан (СОП, янгыннан зыян күрүчеләр) тыш, Кужак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 500 сум күләмендә узара салым кертү һәм җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә тоту белән килешәсезме?:

1) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен җиһазларны тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау;

2) урамнарны яктырту эшләрен оештыру;

3) су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су коймасын тәэмин итә

торган башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, халыкка су ташу һәм су бирү системаларын проектлау;
4) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
5) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
6) халыкның күплэп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, яр буйлары, пляжлар, спорт мәйданчыклары һәм халыкның күплэп ял итү өчен башка урыннар) ремонтлау һәм алар янәшәсендәге территорияләрне төзекләндерү;

ӘЙЕ ЮК?»

3.Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында (http:// sarmanovo. tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башлыгы А.Н.Габдрахманов